КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 апрель г.Казань № 463

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча, шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү чаралары турында» 2011 ел, 10 июнь, 463 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча, шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә

мониторинг оештыру һәм үткәрү чаралары турында» 2011 ел, 10 июнь, 463 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 август, 625 нче; 2015 ел, 11 ноябрь, 844 нче; 2016 ел, 9 июнь, 375 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2018 ел, 16 ноябрь, 1001 нче; 2021 ел, 15 июнь, 453 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның унынчы абзацында «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча, шулай ук мониторинг үткәрергә вәкаләтле органның башка дәүләт органнары белән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат урнаштыру (бирү) регламентында «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин